**«РАСЛЫЙМ»**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры**

**____________ Э.Н. Фәттахов**

**«24» ноябрь 2016 ел**

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2017 нче елда татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрүнең әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

**Рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларның татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2017 нче елда татар теленнән төп дәүләт имтиханын үткәрүнең әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы**

Татар теленнән әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – 2017 нче елда төп дәүләт имтиханын үткәрүнең эчтәлеген билгеләүче документларның берсе. Кодификатор ике бүлектән тора:

1 нче бүлек – төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән төп дәүләт имтиханында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге;

2 нче бүлек – төп гомуми белем бирү мәктәбе курсы буенча татар теленнән төп дәүләт имтиханының әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге.

Кодификаторда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, белем бирү программаларына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Бу документ татар теле буенча төп гомуми белем бирү мәктәп курсы кысаларында төп дәүләт имтиханын уздыру өчен нигез булып тора, шуңа күрә уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

## 1 нче бүлек. Татар теленнән төп дәүләт имтиханында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге

| **Бүлек коды** | **Тикшерелә торган элемент коды** | **Тикшерелә торган материалның эчтәлеге** |
|---|---|---|
| **1** | | **А-Л темалары буенча сөйләшү (Искәрмәне карагыз)** |
| **1.1** | | **Монологик сөйләм** |
| | 1.1.1 | Сөйләмнең төп коммуникатив төрләрен кулланып, төрле фактлар һәм вакыйгалар турында сөйләү (тасвирлау/характеристика, хикәяләү/хәбәрләмә, хисле фикер йөртү) |
| | 1.1.2 | Укылган текст буенча хәбәрләмә |

| | | |
|---|---|---|
| **2** | | **Сөйләмнең лексик-грамматик үзенчәлекләре** |
| **2.1** | | **Сөйләмнең фонетик үзенчәлекләре** |
| | 2.1.1 | Татар теленең барлык авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтү; сүздәге һәм җөмләдәге басымны дөрес куеп сөйләү; җөмләне мәгънәви төркемнәргә бүлү. |
| | 2.1.2 | Төрле җөмләләрдәге дөрес интонацияне саклау. |
| **2.2** | | **Сөйләмнең грамматик үзенчәлекләре** |
| | 2.2.1 | Җөмләнең әйтү максаты буенча төрләре (хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр) һәм аларда сүз тәртибе |
| | 2.2.2 | Җәенке һәм җыйнак җөмләләр |
| | 2.2.3 | Тезмә кушма җөмләләр |
| | 2.2.4 | Иярченле кушма җөмләләр |
| | 2.2.5 | Туры һәм кыек сөйләм |
| | 2.2.5 | Җөмләнең грамматик (предикатив) нигезе. Баш кисәкләр (ия, хәбәр). Иярчен кисәкләр |
| | 2.2.6 | Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр |
| | 2.2.7 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр |
| | 2.2.8 | Тулы һәм ким җөмләләр |
| | 2.2.9 | Гади җөмлә |
| | 2.2.10 | Сүзтезмәгә |
| | 2.2.11 | Кушма җөмлә |
| **2.3** | | **Сөйләмнең лексик үзенчәлекләре** |
| | 2.3.1 | Сүзләрнең туры hзм күчерелмә мәгънәләре. Антонимнар. Синонимнар. |
| | 2.3.2 | Фразеологик әйтелмәләр |
| 3 | | ***Орфография*** |
| | 3.1 | е, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 3.2 | о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 3.3 | в хәрефенең дөрес язылышы |

| | | |
|---|---|---|
| | 3.4 | ъ-ь билгеләренең дөрес язылышы |
| | 3.5 | къ-гъ, к-г авазларын дөрес язу кагыйдәләре |
| | 3.6 | э хәрефенең дөрес язылышы |
| | 3.7 | сүз азагындагы [п] һәм [к], [къ] авазларының дөрес язылышы |
| | 3.8 | Дифтонгларның дөрес язылышы |
| | 3.9 | Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләре |
| | 3.10 | -ия, -ие, -ль гә беткән алынма сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 3.11 | Баш хәрефләрне язу кагыйдәләре |
| | 3.12 | Саннарның дөрес язылышы |
| | 3.13 | Инфинитивның дөрес язылышы |
| | 3.14 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы |
| | 3.15 | Тезмә, парлы, кушма сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 3.16 | Кушымчаларның дөрес язылышы |
| | 3.17 | Орфографик принциплар |
| **4** | | ***Пунктуация*** |
| | 4.1 | Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе |
| | 4.2 | Гади җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.3 | Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре |
| | 4.4 | Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре |
| | 4.5 | Аерымланган кисәкләр янында тыныш билгеләре |
| | 4.6 | Аныклагычлар янында тыныш билгеләре |
| | 4.7 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре янында куела торган тыныш билгеләре |
| | 4.8 | Туры сөйләм һәм диалогта тыныш билгеләре |
| | 4.9 | Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре |
| | 4.10 | Кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.11 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.12 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.13 | Аналитик иярчен җөмләле кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.14 | Синтетик иярчен җөмләле кушма җөмләдә тыныш билгеләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 4.15 | Катлаулы кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 4.16 | Тезем һәм чит сөйләмле текстларда тыныш билгеләре |
| | 4.17 | Диалогта тыныш билгеләре |
| | 4.18 | Туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләре |
| | 4.19 | Татар һәм рус телләрендә пунктуация үзенчәлекләре |
| **5** | | ***Татар сөйләменең матурлыгы*** |
| | 5.1 | Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы |
| | 5.2 | Лексика һәм фразеологиянең тәэсирлелек чаралары |
| | 5.3 | Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү |
| 6 | | **Төрле стильдәге һәм жанрдагы текстларны тикшерү** |
| | | **Искәрмә** |
| | | **Темалар** |
| | А | Гаиләдәге мөнәсәбәтләр |
| | Ә | Дуслар арасындагы мөнәсәбәтләр |
| | Б | Кешенең тышкы кыяфәте |
| | В | Ял һәм мавыгулар (спорт, музыка, уку, кинотеатрга, театрга йөрү) |
| | Г | Мәктәп тормышы |
| | Д | Һөнәр сайлау |
| | Е | Танылган кешеләр |
| | Ж | Сәяхәт итү |
| | З | Заманның глобаль проблемалары |
| | И | Массакүләм мәгълүмат чаралары |
| | К | Табигать һәм экология проблемалары |
| | Л | Сәламәт яшәү рәвеше |

## 2 нче бүлек. Татар теленнән төп дәүләт имтиханына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

| Таләп коды | Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге |
|---|---|
| 1. | Сүзнең аваз-хәреф мөнәсәбәте үзенчәлекләрен белү |
| 2. | Сөйләмне татар әдәби теленең әйтелеш (орфоэпик) нормалары ягыннан бәяли белү |
| 3. | Сөйләмне татар әдәби теленең лексик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 4. | Сөйләмне татар әдәби теленең морфологик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 5. | Сөйләмне татар әдәби теленең синтаксик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 6. | Сөйләмне аңлап, дөрес тәрҗемә итә белү |

| | |
|---|---|
| 7. | Грамматик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү |
| 8. | Лексик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү |
| 9. | Сүзгә фонетик анализ ясый белү |
| 10. | Фонетика, лексика, сүз ясалышы, морфология, синтаксис буенча алган белемнәрен телнең орфографик нормаларына яраклаштырып куллана белү |
| 11. | Тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү |
| 12. | Сөйләм эшчәнлеге барышында, татар теленең синтаксик нормаларыннан тайпылмау |
| 13. | Язма сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү |
| 14. | Сөйләм стильләрен белү |
| 15. | Сүз ясалышы ысулларын белү |
| 16. | Сүзтезмә һәм аның төрләре турында белү |
| 17. | Җөмлә һәм аның үзенчәлекләре турында белү |
| 18. | Текстның эчтәлеге турында кыскача төгәл мәгълүмат бирә белү |
| 19. | Башлангыч текстның эчтәлеген аңлый һәм аңлатып бирә белү |
| 20. | Башлангыч текстка нигезләп,үз фикереңне эзлекле белдерә белү |
| 21. | Үз фикереңне эзлекле, бәйләнешле белдерә алу |
| 22. | Сөйләмдә телнең лексик байлыгыннан, төрле грамматик конструкцияләрдән урынлы куллана белү |
| 23. | Язма һәм телдән сөйләмне әдәби телнең орфографик, грамматик һәм пунктуацион нормалары нигезендә төзи белү |